КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2022 ел, 13 июнь | г.Казань | № 554

Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә һәм капиталь ремонтлауга дәүләт ярдәме чаралары турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актлары һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларындагы аерым нигезләмәләре үз көчен югалткан дип тану турында» 2020 елның 18 сентябрендәге 1492 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2013 – 2025 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 8 апрель, 235 нче карары белән расланган «2013 – 2025 елларга Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» дәүләт программасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Ындыр табагы хуҗалыклары объектларын төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау эшләрен башкару белән бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау

өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе;

Азык үзәкләрен төзү эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе;

Кимендә 200 баш куәтле сыер абзарларына капиталь ремонт эшләрен башкаруга һәм саву-сөт блоклары төзүгә бәйле чыгымнар өлешен каплауга авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе;

Машина-трактор паркларын капиталь ремонтлауга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе;

140 баштан 390 башка кадәр егәрлекле сыерлар абзарлары һәм 500 баштан һәм 5000 башка кадәр егәрлекле сарыкчылык фермаларын төзү эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе;

Силос-печән траншеяларын ясау эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе;

Яшелчә-бәрәңге саклагычларны капиталь ремонтлау эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә һәм кулланучылар кооперациясе предприятиеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Яшелчә-бәрәңге саклагычларны капиталь ремонтлау эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә һәм кулланучылар кооперациясе предприятиеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 3 август, 678 нче;

«140 баштан 390 башка кадәр егәрлекле сыерлар абзарлары һәм 500 баштан һәм 5000 башка кадәр егәрлекле сарыкчылык фермаларын төзү эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 10 август, 697 нче;

«Силос-печән траншеяларын ясау эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 24 август, 776 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «140 баштан 390 башка кадәр егәрлекле сыерлар абзарлары һәм 500 баштан һәм 5000 башка кадәр егәрлекле сарыкчылык фермаларын төзү эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2021 ел, 10 август,

697 нче карары белән расланган 140 баштан 390 башка кадәр егәрлекле сыерлар абзарлары һәм 500 баштан һәм 5000 башка кадәр егәрлекле сарыкчылык фермаларын төзү эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2021 ел, 20 декабрь, 1253 нче;

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә, әлеге карар белән расланган Ындыр табагы хуҗалыклары объектларын төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау эшләрен башкару белән бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенең 6 пунктының өченче абзацыннан, 20 пунктыннан, Азык үзәкләрен төзү эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенең 6 пунктының өченче абзацыннан, 20 пунктыннан, Кимендә 200 баш куәтле сыер абзарларына капиталь ремонт эшләрен башкаруга һәм саву-сөт блоклары төзүгә бәйле чыгымнар өлешен каплауга авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенең 6 пунктының өченче абзацыннан, 20 пунктыннан, Машина-трактор паркларын капиталь ремонтлауга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенең 6 пунктының өченче абзацыннан, 20 пунктыннан, 140 баштан 390 башка кадәр егәрлекле сыерлар абзарлары һәм 500 баштан һәм 5000 башка кадәр егәрлекле сарыкчылык фермаларын төзү эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенең 6 пунктының өченче абзацыннан, 20 пунктыннан, Силос-печән траншеяларын ясау эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенең 6 пунктының өченче абзацыннан, 20 пунктыннан, Яшелчә-бәрәңге саклагычларны капиталь ремонтлау эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә һәм кулланучылар кооперациясе предприятиеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенең 6 пунктының өченче абзацыннан, 20 пунктыннан тыш, алар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көчләренә керә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 13 июнь, 554 нче карары белән расланды

Ындыр табагы хуҗалыклары объектларын төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау эшләрен башкару белән бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш) хисап һәм (яисә) агымдагы финанс елларда башкарылган ындыр табагы хуҗалыклары объектларын төзү, реконструкцияләү һәм капиталь ремонтлау: ашлык складлары, ашлык саклагычлар, орлыксаклагычлар, ындыр табаклары төзү эшләренең үтәлешенә бәйле чыгымнар өлешен (җиһазлар сатып алуга һәм өстәлгән бәягә салым түләүгә чыгымнарны тотып калып) каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү механизмын билгели (алга таба - тиешенчә субсидияләр, сайлап алуда катнашучылар).

2. Субсидия бирү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен бюджет акчасын алучы буларак бюджет акчасы белән баш эш итүчегә – Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

Субсидия турында мәгълүматлар Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы проектын (Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы проектын) формалаштырганда Министрлык тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә урнаштырыла.

3. Субсидия алучылар Министрлык тарафыннан, сайлап алуда катнашучыларның сайлап алу критерийларына туры килүеннән һәм заявкалар керү чиратыннан чыгып, сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучылар җибәргән тәкъдимнәрне (заявкаларны) (алга таба – заявкалар) соратып алу юлы белән үткәрелә торган сайлап алу нәтиҗәләре буенча билгеләнә.

4. Министрлык бердәм порталда һәм үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында https://agro.tatarstan.ru (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты), сайлап алуны үткәрү срогы башлану көненә кадәр өч календарь көннән дә соңга калмыйча, түбәндәгеләрне күрсәтеп, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыра:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкаларны кабул итә башлау яки сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән дә иртәрәк була алмаган заявкаларны кабул итү тәмамлану датасы (2022 елда заявкаларны кабул итү тәмамлану срогы сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң

килә торган 10 календарь көнгә кадәр кыскартылырга мөмкин);

Министрлыкның исемен, урнашу урынын, почта адресын, электрон почта адресын;

бу Тәртипнең 15 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәләрен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин итеlә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

бу Тәртипнең 6 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләрне һәм аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм бу Тәртипнең 7 пункты нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

бу Тәртипнең 8 һәм 9 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) имза куелырга тиешле срокны;

сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) килешү төзүдән баш тарткан (читләшкән) дип тану шартларын;

сайлап алу нәтиҗәләренең бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алуда җиңүчене билгеләгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңрак булмаган урнаштыру датасын.

5. Субсидия алучыларны сайлап алу критерийлары түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бару һәм Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түләү;

Икътисадый эшчәнлек төрләренең гомумроссия классификаторында каралган икътисадый эшчәнлекнең бер яисә берничә төрен гамәлгә ашыру (ОК 029-2014 (КДЕС Ред. 2) – 01.1, 01.4, 01.5);

төзелгән яисә реконструкцияләнгән, хисап һәм (яисә) агымдагы финанс елларында капиталь ремонт үткәрелгән ындыр табаклары хуҗалыклары объектлары милкендә булу;

үзлегеннән җайга салына торган оешмага кертелгән ындыр табаклары хуҗалыклары объектларын төзегәндә, төзекләндергәндә һәм капиталь ремонт ясаганда төзелеш контроле үткәрү һәм әлеге эшне башкаручы белгечләр Төзелеш өлкәсендәге белгечләрнең илкүләм реестрына кертелгән шарт белән.

6. Сайлап алуда катнашучы заявка бирү датасына түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмау (2022 елда сайлап алуда

катнашучы салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча 300 мең сумнан артмаган, түләнмәгән бурыч булырга мөмкин);

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнмәгән бурычлар, шулай ук Татарстан Республикасы каршында акча йөкләмәләре буенча вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычлар юк;

сайлап алуда катнашучылар-юридик затлар үзгәртеп кору процессында (сайлап алуда катнашучы юридик затка кушылу формасында үзгәртеп корудан тыш), банкротлык процедурасы кертелмәгән ликвидация процессында (сайлап алуда катнашучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган, ә сайлап алуда катнашучылар-индивидуаль эшкуарлар индивидуаль эшкуар буларак эшчәнлеген туктатырга тиеш түгел;

чит ил юридик заты, шулай ук Россия Федерациясе Финанс министрлыгы расланган, салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләрен уздырганда мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмаган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган, устав (җыелма) капиталында чит илләр юридик затларының катнашу өлеше барысы бергә җыеп исәпләгәндә 50 проценттан артмаган Россия юридик заты булмау;

бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмау;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмаска;

2022 елда сайлап алуда катнашучы Россия Федерациясенә, Россия Федерациясе гражданнарына яки Россия юридик затларына карата дусларча булмаган гамәлләр кылучы чит ил дәүләтләре тарафыннан сәяси яки икътисадый санкцияләр кертелү аркасында товарлар кайтарту, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү турында төзелгән дәүләт (муниципаль) контрактларын үтәүдән баш тартуга һәм (яки) чит ил дәүләтләре, чит ил дәүләтләренең дәүләт берләшмәләре һәм (яки) союзлары һәм (яки) дәүләт (дәүләтара) учреждениеләре яки дәүләт берләшмәләре һәм (яки) союзлары тарафыннан чикләү характерындагы чаралар кертелүгә бәйле рәвештә, намуссыз тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) реестрында булмаска тиеш.

7. Субсидия алуга сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучы http://subsidiya.tatar.ru яки http://subsidiya.tatarstan.ru адресы буенча «Минем субсидияләр» мәгълүмат системасының рәсми сайтында (алга таба – сервис) йә «Минем субсидияләр» мобиль кушымтасында, Бердәм дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталының (www.gosuslugi.ru) «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмат-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада идентификацияләүнең һәм аутентификацияләүнең бердәм

системасы» мәгълүмат системасында расланган теркәлү язуыннан файдаланып, шәхси кабинет булдыра, аның түләү реквизитлары һәм почта адресы күрсәтелгән, шул исәптән сайлап алуда катнашучының бу Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турында мәгълүмат, сайлап алуда катнашучының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлауда катнашучы турындагы, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелә торган заявка турындагы мәгълүматны һәм сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алу белән бәйле булган башка мәгълүматны бастырып чыгару, шулай ук шәхси мәгълүматларны (физик затлар өчен) эшкәртү өчен ризалыгы бирелгән, Министрлык боерыгы белән расланган формада языла торган заявка тутыра һәм түбәндәге документларның сканер ярдәмендә алынган күчермәләрен сервиска кертәләр:

ындыр табагы хуҗалыклары объектларын төзегәндә һәм (яисә) реконструкциялəгәндә:

капиталь төзелеш объектының проект документациясенә һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе;

капиталь төзелеш объекты төзелешенең смета кыйммәтен билгеләү дөреслеген тикшерү өлешендә проект документациясенә дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе (аерым тора торган, катлар саны иң күбе ике булган, гомуми мәйданы иң күбе 1 500 кв.метр тәшкил иткән капиталь төзелеш объектлары өчен);

төзелешкә һәм (яисә) реконструкциягә рөхсәт;

эшләр башкару сыйфатына һәм күләмнәренә төзелеш контролен гамәлдә ашыруны күздә тота торган шартнамә;

җыелма смета исәп-хисабы;

локаль смета исәп-хисаплар;

төзелеш-монтаж эшләрен башкаруга подряд шартнамәләре;

төзелеш контролен гамәлгә ашыручы оешма белән проект документациясенең башкарылган эшләренә оешма белән туры килүенә килештерелгән «Башкарылган эшләрне кабул итү турында акт» дигән КС-2 нче статистик форма буенча белешмә кәгазьләре;

«Башкарылган эшләр һәм чыгымнар кыйммәтләре турында белешмә кәгазе» дигән КС-3 нче статистик форма буенча белешмә кәгазьләрен;

хисап һәм (яки) агымдагы финанс елында башкарылган эшләр өчен түләүне раслый торган түләү йөкләмәләре;

хисап финанс елыннан алданрак алынган объектны файдалануга тапшыруга рөхсәтнамә;

хисап финанс елыннан иртәрәк алынмаган ындыр табагы хуҗалыклары объектлары милкендә булуын раслый торган документлар;

ындыр табагы хуҗалыклары объектларына капиталь ремонт ясаганда:

капиталь төзелеш объектын капиталь ремонтлауның смета бәясен билгеләүнең дөреслеген тикшерү өлешендә проект документациясенә дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсен;

эшләр башкару сыйфатына һәм күләмнәренә төзелеш контролен гамәлдә ашыруны күздә тота торган шартнамә;

җыелма смета исәп-хисабы;

локаль смета исәп-хисаплар;

төзелеш-монтаж эшләрен башкаруга подряд шартнамәләре;

төзелеш контролен гамәлгә ашыручы оешма белән проект документациясенең башкарылган эшләренә оешма белән туры килүенә килештерелгән «Башкарылган эшләрне кабул итү турында акт» дигән КС-2 нче статистик форма буенча белешмә кәгазьләре;

«Башкарылган эшләр һәм чыгымнар кыйммәтләре турында белешмә кәгазе» дигән КС-3 нче статистик форма буенча белешмә кәгазьләрен;

хисап һәм (яки) агымдагы финанс елында башкарылган эшләр өчен түләүне раслый торган түләү йөкләмәләре;

милектә ындыр табагы хуҗалыклары объектлары булуын раслый торган документлар.

Сервистан файдаланып тутырылган документларга гади электрон имза куела, гади электрон имзаны куллану турындагы килешү сервиста урнаштырылган оферта шартларын кабул итү юлы белән төзелә.

Әлеге Тәртипнең 5 пунктының икенче һәм өченче абзацларында билгеләнгән критерийларга һәм әлеге Тәртипнең 6 пунктының икенче, дүртенче һәм бишенче абзацларында билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәүгә сайлап алуда катнашучыны тикшерү ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә алына торган мәгълүмат нигезендә сервиста автоматик режимда гамәлгә ашырыла.

Сайлап алуда катнашучы заявканы сайлап алу тәмамланганчы теләсә кайсы вакытта, шул исәптән сервиста сайлап алуда катнашучының бер яисә берничә критерийга яисә таләпләргә туры килмәве турында мәгълүмат алган очракта, сервиста аның туры килүен автоматик режимда тикшерү башкарыла.

Сайлап алуда катнашучы, кирәк булганда, заявкалар кабул итү өчен билгеләнгән срок эчендә заявканы кабат бирергә хокуклы, шул ук вакытта заявка кергән көнендә чират тәртибендә теркәүгә алына.

8. Министрлык:

заявкалар кабул итү турындагы белдерүдә күрсәтелгән сайлап алуны үткәрү срогы тәмамланган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган унбиш көн эчендә аларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән критерийларга һәм таләпләргә туры килү-килмәвен карап тикшерә, Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча сайлап алу нәтиҗәләре турында реестр төзи һәм сайлап алуда җиңүче билгеләү турында йә заявканы алудан баш тарту турында карар кабул итә;

сайлап алуда җиңүчеләрне билгеләгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңга калмыйча, түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алган сайлап алу нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыра:

заявкаларны карап тикшерү датасы, вакыты һәм үткәрү урыны;

заявкалары карап тикшерелгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килми торган нигезләмәләрен күрсәтеп, заявкалары кабул итүдән баш тартылган сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

килешү төзелә торган субсидия алучының (алучыларның) исеме һәм аңа бирелә торган субсидия күләме.

9. Заявкаларны карап тикшерү стадиясендә заявканы алмау өчен түбәндәгеләр нигез була:

сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 6 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан тапшырылган заявканың һәм документларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән заявкаларга карата таләпләргә туры килмәве;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның, шул исәптән юридик затның урнашу урыны һәм адресы турындагы мәгълүматның дөрес булмавы;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан заявканың аны бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң бирелүе;

сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 5 пунктында билгеләнгән критерийларга туры килмәве;

бюджет йөкләмәләре лимитының сарыф итеп бетерелүе.

10. Министрлык бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алу нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштырылган көннән биш эш көне эчендә субсидия алучылар белән Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгы билгеләгән бертип форма нигезендә килешү төзи.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше, күчерү тәртибе;

субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләре;

субсидия алучы тарафыннан Министрлык билгеләгән өстәмә хисапларны бирү формасы һәм сроклары;

субсидияне кире кайтару тәртибе;

бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән, элек җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкинлеген булдырмауга китерә торган итеп Министрлыкка киметкән очракта, килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар белән ризалашуга ирешә алмаганда килешүне өзү турында шарт (2022 елда килешүнең яңа шартларын, шул исәптән кирәк булганда, башкарма хакимиятнең билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль органы килешү ягы булып тормаган очракта, әлеге орган вәкилләре катнашында килештерү тәртибе).

Кирәк булганда Министрлык субсидия алучылар белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән бертип формалар нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

11. Әлеге Тәртипнең 10 пунктының беренче абзацында күрсәтелгән срокларда субсидия алучы исеменнән эш итәргә хокукы булган зат имзасы белән килешү проектын Министрлыкка тапшырмаган очракта, субсидия алучы килешү төзүдән читләшкән дип таныла.

12. Министрлык:

сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә килешүләргә имза кую срогы чыккан көннән бишенче эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкның боерыгы

белән рәсмиләштерелә торган субсидия алучыларга субсидия бирү турында карар кабул итә;

субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә акчаны үзенең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счетыннан субсидия алучылар өчен Россия Федерациясе Үзәк банкы яки кредит оешмалары учреждениеләрендә ачылган исәп-хисап яки корреспондентлык счетларына күчерүне гамәлгә ашыра.

13. Субсидия кире кайтару өчен бирелә торган чыгымнар юнәлешләре - КС-2 номерлы форма буенча башкарылган эшләрне кабул итү турындагы актларга кертелгән ындыр табаклары хуҗалыклары объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә яисә реконструкцияләүгә, яисә капиталь ремонтлауга бәйле төзелеш, монтаж һәм башка эш төрләренә чыгымнар (җиһазлар сатып алуга һәм өстәлгән бәягә салым түләүгә чыгымнарны тотып калып).

14. Әлеге Тәртипнең 1 пункты (W) (сумнарда) нигезендә субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W = \sum_{i=1}^{n} (P \times 0,3),$$

монда:

i - ындыр табагы хуҗалыклары объектлары;

n - ындыр табагы хуҗалыкларының объектлары саны;

P - хисап һәм (яисә) агымдагы финанс елларда ындыр табагы хуҗалыгы объектын төзүгә, яисә реконструкцияләүгә, яисә капиталь ремонтлауга бәйле төзелеш, монтаж һәм башка төр эшләр өчен түләүгә фактагы чыгымнар, алар КС-2 формасы буенча башкарылган эшләрне кабул итү турындагы актларга кертелгән (өстәлгән бәягә салымны һәм җиһазлар сатып алуны исәпкә алмыйча), сум.

Субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме ындыр табагы хуҗалыгы объектын төзүгә, реконструкцияләүгә һәм капиталь ремонтлауга смета бәясенең 30 процентыннан арта алмый, моңа җиһазлар сатып алуга һәм өстәмә кыйммәткә салым түләүгә чыгымнар керми.

15. Субсидия бирү нәтиҗәләре түбәндәгеләр:

агымдагы финанс елның 31 декабренә торышы буенча ындыр табагы хуҗалыклары объектларының файдалануга тапшырылган саны (берәмлек);

агымдагы финанс елның 31 декабренә торышы буенча капиталь ремонт ясалган ындыр табаклары хуҗалыклары объектлары саны (берәмлек) .

2022 елда субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә килешүдә билгеләгән срокларда ирешү мөмкинлеге булмауга китерә торган шартлар барлыкка килгән очракта, Министрлык, субсидия алучы белән килештереп, субсидия күләмен үзгәртмичә, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү срокларын (әмма иң күбе 24 айга) озайту өлешендә килешүгә үзгәрешләр кертү турында карар кабул итәргә хокуклы. Субсидия күләмен үзгәртмичә, субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү мөмкинлеге булмаган очракта, Министрлык субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткечен киметү турында карар кабул итәргә хокуклы.

16. Субсидия алучы Министрлыкка субсидия бирү нәтиҗәләре мәгънәсенә ирешү турында, субсидия алу елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр,

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән типлаштырылган килешү формасы буенча хисап тапшыра.

17. Бирелгән субсидия Министрлыкның тиешле хәбәрнамәсе алынган көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемenә кире кайтарылырга тиеш:

тулы күләмдә – субсидия алучы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы факты ачыкланган, субсидия бирелгәндә билгеләнгән, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча шартлар бозылган, субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап бирелмәгән очракларда;

субсидия алучы тарафыннан килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешелмәгән очракта, Министрлык субсидия алучыга карата түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла торган штраф санкцияләрен ($V_{кайтару}$) куллана, почта аша тапшыру турындагы хәбәрнамәне теркәп, срогын һәм түләү реквизитларын күрсәтеп, килешүдә билгеләнгән, субсидия бирү нәтиҗәләре мәгънәләренә ирешү турында хисап алынган датадан эш көннәрендә исәпләнә торган 60 көн эчендә штраф санкцияләрен куллану турында хәбәрнамә җибәрә:

$$V_{кире\ кайтару} = (V_{субсидия} \times k) \times 0{,}1,$$

монда:

$V_{субсидия}$ – хисап финанс елында субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү максатларында субсидия алучыга фактта бирелгән субсидия күләме;

k – субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешелмәү дәрәҗәсен чагылдыра, түбәндәге формула буенча билгеләнә торган коэффициент:

$$k = 1 ,\frac{T}{S}$$

монда:

T – хисап датасына субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәсенең фактта ирешелгән күрсәткече;

S – субсидия алучы өчен килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенең план буенча күрсәткече.

Штраф санкцияләрен исәпләп чыгарганда бары субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешмәү дәрәҗәсен чагылдыра торган коэффициентның уңай мәгънәләре кулланыла.

2022 елда килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләренә ирешелмәгән өчен штраф санкцияләре кулланылмый.

18. Субсидия алучы тарафыннан бу Тәртипнең 17 пунктында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару срогы бозылганда, Министрлык субсидияне кире кайтару срогы чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган егерме көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри түләтү буенча чаралар күрә.

19. Министрлык субсидия алучыларның субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.»;

20. Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны төгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча гамәлгә ашырыла.

21. Субсидия алучы тарафыннан Министрлыкка тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык субсидия алучыларның тиешле вазыйфаи затларына һәм җитәкчеләренә йөкләнә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 13 июнь, 554 нче карары белән расланды

Азык үзәкләрен төзү эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш) хисап һәм (яисә) агымдагы финанс елларда башкарылган азык үзәкләрен төзү эшләренең үтәлешенә бәйле чыгымнар өлешен (җиһазлар сатып алуга һәм өстәлгән бәягә салым түләүгә чыгымнарны тотып калып) каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү механизмын билгели (алга таба - тиешенчә субсидияләр, сайлап алуда катнашучылар).

Әлеге Тәртипне куллану максатларында азык үзәге дигәндә, тупас, сусыл һәм катнаш азыклардан беришле катнашма әзерләү өчен стационар миксеры белән җиһазланган капиталь төзелеш объекты аңлашыла.

2. Субсидия бирү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен бюджет акчасын алучы буларак бюджет акчасы белән баш эш итүчегә – Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

Субсидия турында мәгълүматлар Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы проектын (Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы проектын) формалаштырганда Министрлык тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә урнаштырыла.

3. Субсидия алучылар Министрлык тарафыннан, сайлап алуда катнашучыларның сайлап алу критерийларына туры килүеннән һәм заявкалар керү чиратыннан чыгып, сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучылар җибәргән тәкъдимнәрне (заявкаларны) (алга таба – заявкалар) соратып алу юлы белән үткәрелә торган сайлап алу нәтиҗәләре буенча билгеләнә.

4. Министрлык бердәм порталда һәм үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында https://agro.tatarstan.ru (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты), сайлап алуны үткәрү срогы башлану көненә кадәр өч календарь көннән дә соңга калмыйча, түбәндәгеләрне күрсәтеп, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыра:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкаларны кабул итә башлау яки сайлап алуны үткәрү турында белдерү

урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән дә иртәрәк була алмаган заявкаларны кабул итү тәмамлану датасы (2022 елда заявкаларны кабул итү тәмамлану срогы сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 календарь көнгә кадәр кыскартылырга мөмкин);

Министрлыкның исемен, урнашу урынын, почта адресын, электрон почта адресын;

бу Тәртипнең 15 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин итеlә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

бу Тәртипнең 6 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләрне һәм аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм бу Тәртипнең 7 пункты нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

бу Тәртипнең 8 һәм 9 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) имза куелырга тиешле срокны;

сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) килешү төзүдән баш тарткан (читләшкән) дип тану шартларын;

сайлап алу нәтиҗәләренең бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алуда җиңүчене билгеләгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңрак булмаган урнаштыру датасын.

5. Субсидия алучыларны сайлап алу критерийлары түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бару һәм Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түләү;

Икътисадый эшчәнлек төрләренең гомумроссия классификаторында каралган икътисадый эшчәнлекнең бер яисә берничә төрен гамәлгә ашыру (ОК 029-2014 (КДЕС Ред. 2) – 01.4, 01.5);

хисап һәм (яисә) агымдагы финанс елларда төзелгән, кимендә 5 тонна/сәгать егәрлеге белән стационар миксерлар белән тәэмин ителгән азык үзәкләре, азык туплау буенча һөнәри программа тәэмин ителеше, азык компонентын бирүнең системасы (җайланмасы) булу;

үзлегеннән җайга салына торган оешмага кертелгән терлек азыгы үзәкләрен төзегәндә төзелеш контроле үткәрү һәм әлеге эшне башкаручы белгечләр Төзелеш өлкәсендәге белгечләрнең илкүләм реестрына кертелгән шарт белән.

6. Сайлап алуда катнашучы заявка бирү датасына түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә

түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмау (2022 елда сайлап алуда катнашучы салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча 300 мең сумнан артмаган, түләнмәгән бурыч булырга мөмкин);

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнмәгән бурычлар, шулай ук Татарстан Республикасы каршында акча йөкләмәләре буенча вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычлар юк;

сайлап алуда катнашучылар-юридик затлар үзгәртеп кору процессында (сайлап алуда катнашучы юридик затка кушылу формасында үзгәртеп корудан тыш), банкротлык процедурасы кертелмәгән ликвидация процессында (сайлап алуда катнашучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган, ә сайлап алуда катнашучылар-индивидуаль эшкуарлар индивидуаль эшкуар буларак эшчәнлеген туктатырга тиеш түгел;

чит ил юридик заты, шулай ук Россия Федерациясе Финанс министрлыгы расланган, салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләрен уздырганда мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмаган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган, устав (җыелма) капиталында чит илләр юридик затларының катнашу өлеше барысы бергә җыеп исәпләгәндә 50 проценттан артмаган Россия юридик заты булмау;

бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмау;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмаска;

2022 елда сайлап алуда катнашучы Россия Федерациясенә, Россия Федерациясе гражданнарына яки Россия юридик затларына карата дусларча булмаган гамәлләр кылучы чит ил дәүләтләре тарафыннан сәяси яки икътисадый санкцияләр кертелү аркасында товарлар кайтарту, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү турында төзелгән дәүләт (муниципаль) контрактларын үтәүдән баш тартуга һәм (яки) чит ил дәүләтләре, чит ил дәүләтләренең дәүләт берләшмәләре һәм (яки) союзлары һәм (яки) дәүләт (дәүләтара) учреждениеләре яки дәүләт берләшмәләре һәм (яки) союзлары тарафыннан чикләү характерындагы чаралар кертелүгә бәйле рәвештә, намуссыз тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) реестрында булмаска тиеш.

7. Субсидия алуга сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучы http://subsidiya.tatar.ru яки http://subsidiya.tatarstan.ru адресы буенча «Минем субсидияләр» мәгълүмат системасының рәсми сайтында (алга таба – сервис) йә «Минем субсидияләр» мобиль кушымтасында, Бердәм дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталының (www.gosuslugi.ru) «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен кулланыла

торган мәгълүмат системаларының мәгълүмат-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада идентификацияләүнең һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» мәгълүмат системасында расланган теркәлү язуыннан файдаланып, шәхси кабинет булдыра, аның түләү реквизитлары һәм почта адресы күрсәтелгән, шул исәптән сайлап алуда катнашучының бу Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турында мәгълүмат, сайлап алуда катнашучының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлауда катнашучы турындагы, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелә торган заявка турындагы мәгълүматны һәм сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алу белән бәйле булган башка мәгълүматны бастырып чыгару, шулай ук шәхси мәгълүматларны (физик затлар өчен) эшкәртү өчен ризалыгы бирелгән, Министрлык боерыгы белән расланган формада языла торган заявка тутыра һәм түбәндәге документларның сканер ярдәмендә алынган күчермәләрен сервиска кертәләр:

капиталь төзелеш объектының проект документациясенә һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе;

капиталь төзелеш объекты төзелешенең смета кыйммәтен билгеләү дөреслеген тикшерү өлешендә проект документациясенә дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе (аерым тора торган, катлар саны иң күбе ике булган, гомуми мәйданы иң күбе 1 500 кв.метр тәшкил иткән капиталь төзелеш объектлары өчен);

төзелешкә рөхсәт;

эшләр башкару сыйфатына һәм күләмнәренә төзелеш контролен гамәлдә ашыруны күздә тота торган шартнамә;

җыелма смета исәп-хисабы;

локаль смета исәп-хисаплар;

төзелеш-монтаж эшләрен башкаруга подряд шартнамәләре;

төзелеш контролен гамәлгә ашыручы оешма белән проект документациясенең башкарылган эшләренә оешма белән туры килүенә килештерелгән «Башкарылган эшләрне кабул итү турында акт» дигән КС-2 нче статистик форма буенча белешмә кәгазьләре;

«Башкарылган эшләр һәм чыгымнар кыйммәтләре турында белешмә кәгазе» дигән КС-3 нче статистик форма буенча белешмә кәгазьләрен;

хисап һәм (яки) агымдагы финанс елында башкарылган эшләр өчен түләүне раслый торган түләү йөкләмәләре;

хисап финанс елыннан алданрак алынган объектны файдалануга тапшыруга рөхсәтнамә;

хисап финанс елыннан иртәрәк алынмаган үз азык үзәкләре милкендә булуын раслый торган документлар;

технологик җиһазларга техник паспорт (азык катнашмасы, ашлык ваклау, үлчәү, транспортер);

№ ОС-15 статистик формасы буенча җиһазларны монтажлау акты.

Сервистан файдаланып тутырылган документларга гади электрон имза куела, гади электрон имзаны куллану турындагы килешү сервиста урнаштырылган оферта шартларын кабул итү юлы белән төзелә.

Әлеге Тәртипнең 5 пунктының икенче һәм өченче абзацларында билгеләнгән критерийларга һәм әлеге Тәртипнең 6 пунктының икенче, дүртенче һәм бишенче абзацларында билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәүгә сайлап алуда катнашучыны тикшерү ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә алына

торган мәгълүмат нигезендә сервиста автоматик режимда гамәлгә ашырыла.

Сайлап алуда катнашучы заявканы сайлап алу тәмамланганчы теләсә кайсы вакытта, шул исәптән сервиста сайлап алуда катнашучының бер яисә берничә критерийга яисә таләпләргә туры килмәве турында мәгълүмат алган очракта, сервиста аның туры килүен автоматик режимда тикшерү башкарыла.

2022 елда сайлап алуда катнашучы Россия Федерациясенә, Россия Федерациясе гражданнарына яки Россия юридик затларына карата дусларча булмаган гамәлләр кылучы чит ил дәүләтләре тарафыннан сәяси яки икътисадый санкцияләр кертелү аркасында товарлар кайтарту, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү турында төзелгән дәүләт (муниципаль) контрактларын үтәүдән баш тартуга һәм (яки) чит ил дәүләтләре, чит ил дәүләтләренең дәүләт берләшмәләре һәм (яки) союзлары һәм (яки) дәүләт (дәүләтара) учреждениеләре яки дәүләт берләшмәләре һәм (яки) союзлары тарафыннан чикләү характерындагы чаралар кертелүгә бәйле рәвештә, намуссыз тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) реестрында булмаска тиеш.

7. Субсидия алуга сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучы http://subsidiya.tatar.ru яки http://subsidiya.tatarstan.ru адресы буенча «Минем субсидияләр» мәгълүмат системасының рәсми сайтында (алга таба – сервис) йә «Минем субсидияләр» мобиль кушымтасында, Бердәм дәүләт хезмәтләре һәм

муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталының (www.gosuslugi.ru) «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмат-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада идентификацияләүнең һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» мәгълүмат системасында расланган теркәлү язуыннан файдаланып, шәхси кабинет булдыра, аның түләү реквизитлары һәм почта адресы күрсәтелгән, шул исәптән сайлап алуда катнашучының бу Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турында мәгълүмат, сайлап алуда катнашучының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлауда катнашучы турындагы, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелә торган заявка турындагы мәгълүматны һәм сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алу белән бәйле булган башка мәгълүматны бастырып чыгару, шулай ук шәхси мәгълүматларны (физик затлар өчен) эшкәртү өчен ризалыгы бирелгән, Министрлык боерыгы белән расланган формада языла торган заявка тутыра һәм түбәндәге документларның сканер ярдәмендә алынган күчермәләрен сервиска кертәләр:

капиталь төзелеш объектын капиталь ремонтлауның смета бәясен билгеләүнең дөреслеген тикшерү өлешендә проект документациясенә дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсен;

эшләр башкару сыйфатына һәм күләмнәренә төзелеш контролен гамәлдә ашыруны күздә тота торган шартнамә;

җыелма смета исәп-хисабы;

локаль смета исәп-хисаплар;

төзелеш-монтаж эшләрен башкаруга подряд шартнамәләре;

төзелеш контролен гамәлгә ашыручы оешма белән проект документациясенең башкарылган эшләренә оешма белән туры килүенә килештерелгән «Башкарылган эшләрне кабул итү турында акт» дигән КС-2 нче статистик форма буенча белешмә кәгазьләре;

«Башкарылган эшләр һәм чыгымнар кыйммәтләре турында белешмә кәгазе» дигән КС-3 нче статистик форма буенча белешмә кәгазьләрен;

хисап һәм (яки) агымдагы финанс елында башкарылган эшләр өчен түләүне раслый торган түләү йөкләмәләре;

милкендә машина-трактор парклары булуын раслый торган документлар.

Сервистан файдаланып тутырылган документларга гади электрон имза куела, гади электрон имзаны куллану турындагы килешү сервиста урнаштырылган оферта шартларын кабул итү юлы белән төзелә.

Әлеге Тәртипнең 5 пунктының икенче һәм өченче абзацларында билгеләнгән критерийларга һәм әлеге Тәртипнең 6 пунктының икенче, дүртенче һәм бишенче абзацларында билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәүгә сайлап алуда катнашучыны тикшерү ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә алына торган мәгълүмат нигезендә сервиста автоматик режимда гамәлгә ашырыла.

Сайлап алуда катнашучы заявканы сайлап алу тәмамланганчы теләсә кайсы вакытта, шул исәптән сервиста сайлап алуда катнашучының бер яисә берничә критерийга яисә таләпләргә туры килмәве турында мәгълүмат алган очракта, сервиста аның туры килүен автоматик режимда тикшерү башкарыла.

Сайлап алуда катнашучы, кирәк булганда, заявкалар кабул итү өчен билгеләнгән срок эчендә заявканы кабат бирергә хокуклы, шул ук вакытта заявка кергән көнендә чират тәртибендә теркәүгә алына.

8. Министрлык:

заявкалар кабул итү турындагы белдерүдә күрсәтелгән сайлап алуны үткәрү срогы тәмамланган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган унбиш көн эчендә аларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән критерийларга һәм таләпләргә туры килү-килмәвен карап тикшерә, Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча сайлап алу нәтиҗәләре турында реестр төзи һәм сайлап алуда җиңүче билгеләү турында  йә заявканы алудан баш тарту турында карар кабул итә;

сайлап алуда җиңүчеләрне билгеләгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңга калмыйча, түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алган сайлап алу нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыра:

заявкаларны карап тикшерү датасы, вакыты һәм үткәрү урыны;

заявкалары карап тикшерелгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килми торган нигезләмәләрен күрсәтеп, заявкалары кабул итүдән баш тартылган сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

килешү төзелә торган субсидия алучының  (алучыларның) исеме һәм аңа бирелә торган субсидия күләме.

9. Заявкаларны карап тикшерү стадиясендә заявканы алмау өчен түбәндәгеләр нигез була:

сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 6 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан тапшырылган заявканың һәм документларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән заявкаларга карата таләпләргә туры килмәве;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның, шул исәптән юридик затның урнашу урыны һәм адресы турындагы мәгълүматның дөрес булмавы;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан заявканың аны бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң бирелүе;

сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 5 пунктында билгеләнгән критерийларга туры килмәве;

бюджет йөкләмәләре лимитының сарыф итеп бетерелүе.

10. Министрлык бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алу нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштырылган көннән  биш эш көне эчендә субсидия алучылар белән Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгы билгеләгән бертип форма нигезендә килешү төзи.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше, күчерү тәртибе;

субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткече;

субсидия алучы тарафыннан Министрлык билгеләгән өстәмә хисапларны бирү формасы һәм сроклары;

субсидияне кире кайтару тәртибе;

бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән, элек җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкинлеген булдырмауга китерә торган итеп Министрлыкка киметкән очракта, килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар белән ризалашуга ирешә алмаганда килешүне өзү турында шарт (2022 елда килешүнең яңа шартларын, шул исәптән кирәк булганда, башкарма хакимиятнең билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль органы килешү ягы булып тормаган очракта, әлеге орган вәкилләре катнашында килештерү тәртибе).

Кирәк булганда Министрлык субсидия алучылар белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән бертип формалар нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

11. Әлеге Тәртипнең 10 пунктының беренче абзацында күрсәтелгән срокларда субсидия алучы исеменнән эш итәргә хокукы булган зат имзасы белән килешү проектын Министрлыкка тапшырмаган очракта, субсидия алучы килешү төзүдән читләшкән дип таныла.

12. Министрлык:

сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә килешүләргә имза кую срогы чыккан көннән бишенче эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкның боерыгы белән рәсмиләштерелә торган субсидия алучыларга субсидия бирү турында карар кабул итә;

субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә акчаны үзенең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счетыннан субсидия алучылар өчен Россия Федерациясе Үзәк банкы яки кредит оешмалары учреждениеләрендә ачылган исәп-хисап яки корреспондентлык счетларына күчерүне гамәлгә ашыра.

13. Субсидия кире кайтару өчен бирелә торган чыгымнар юнәлешләре - КС-2 номерлы форма буенча башкарылган эшләрне кабул итү турындагы актларга кертелгән машина-трактор паркларына капиталь ремонт ясауга бәйле төзелеш, монтаж һәм башка эш төрләренә чыгымнар (җиһазлар сатып алуга һәм өстәлгән бәягә салым түләүгә чыгымнарны тотып калып).

14. Әлеге Тәртипнең 1 пункты (W) (сумнарда) нигезендә субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W = \sum_{i=1}^{n} (P \times 0{,}3),$$

монда:

i - машина-трактор парклары;

n - машина-трактор парклары саны;

P - хисап һәм (яисә) агымдагы финанс елларда машина-трактор паркларына капиталь ремонт ясауга бәйле төзелеш, монтаж һәм башка төр эшләр өчен түләүгә

фактдагы чыгымнар, алар КС-2 формасы буенча башкарылган эшләрне кабул итү турындагы актларга кертелгән (өстәлгән бәягә салымны һәм җиһазлар сатып алуны исәпкә алмыйча), сум.

Субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме машина-трактор паркын капиталь ремонтлауга смета бәясенең 30 процентыннан артык була алмый, моңа җиһазлар сатып алуга һәм өстәлгән бәягә салым түләүгә чыгымнар керми.

15. Субсидия бирү нәтиҗәсе - машина-трактор паркларының саны, аларда агымдагы финанс елның 31 декабренә (берәмлегенә) капиталь ремонт үткәрелгән.

2022 елда субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә килешүдә билгеләгән срокларда ирешү мөмкинлеге булмауга китерә торган шартлар барлыкка килгән очракта, Министрлык, субсидия алучы белән килештереп, субсидия күләмен үзгәртмичә, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү срокларын (әмма иң күбе 24 айга) озайту өлешендә килешүгә үзгәрешләр кертү турында карар кабул итәргә хокуклы. Субсидия күләмен үзгәртмичә, субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү мөмкинлеге булмаган очракта, Министрлык субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткечен киметү турында карар кабул итәргә хокуклы.

16. Субсидия алучы Министрлыкка субсидия бирү нәтиҗәләре мәгънәсенә ирешү турында, субсидия алу елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән типлаштырылган килешү формасы буенча хисап тапшыра.

17. Бирелгән субсидия Министрлыкның тиешле хәбәрнамәсе алынган көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемена кире кайтарылырга тиеш:

тулы күләмдә – субсидия алучы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы факты ачыкланган, субсидия бирелгәндә билгеләнгән, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча шартлар бозылган, субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешү турында хисап бирелмәгән очракларда;

субсидия алучы тарафыннан килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешелмәгән очракта, Министрлык субсидия алучыга карата түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла торган штраф санкцияләрен ($V_{кайтару}$) куллана, почта аша тапшыру турындагы хәбәрнамәне теркәп, срогын һәм түләү реквизитларын күрсәтеп, килешүдә билгеләнгән, субсидия бирү нәтиҗәләре мәгънәләренә ирешү турында хисап алынган датадан эш көннәрендә исәпләнә торган 60 көн эчендә штраф санкцияләрен куллану турында хәбәрнамә җибәрә:

$$V_{кире\ кайтару} = (V_{субсидия} \times k) \times 0{,}1,$$

монда:

$V_{субсидия}$ – хисап финанс елында субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү максатларында субсидия алучыга фактта бирелгән субсидия күләме;

k – субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешелмәү дәрәҗәсен чагылдыра, түбәндәге формула буенча билгеләнә торган коэффициент:

$$k = 1\ ,\frac{T}{S}$$

монда:

T – хисап датасына субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәсенең фактта ирешелгән күрсәткече;

S – субсидия алучы өчен килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенең план буенча күрсәткече.

Штраф санкцияләрен исәпләп чыгарганда бары субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешмәү дәрәҗәсен чагылдыра торган коэффициентның уңай мәгънәләре кулланыла.

2022 елда килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләренә ирешелмәгән өчен штраф санкцияләре кулланылмый.

18. Субсидия алучы тарафыннан бу Тәртипнең 17 пунктында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару срогы бозылганда, Министрлык субсидияне кире кайтару срогы чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган егерме көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри түләтү буенча чаралар күрә.

19. Министрлык субсидия алучыларның субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.»;

20. Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны тәгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча гамәлгә ашырыла.

21. Субсидия алучы тарафыннан Министрлыкка тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык субсидия алучыларның тиешле вазыйфаи затларына һәм җитәкчеләренә йөкләнә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 13 июнь, 554 нче карары белән расланды

140 баштан 390 башка кадәр егәрлекле сыерлар абзарлары һәм 500 баштан һәм 5000 башка кадәр егәрлекле сарыкчылык фермаларын төзү эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш) хисап һәм (яисә) агымдагы финанс елында башкарылган 140 баштан алып 390 башка кадәр куәтле сыер абзарлары һәм (яисә) 500 дән 5 000 башка кадәр куәтле сарык фермалары төзү эшләрен башкаруга бәйле чыгымнар өлешен каплауга (җиһазлар сатып алуга һәм өстәлгән бәягә салым түләүгә чыгымнардан тыш) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү механизмын билгели (алга таба - субсидияләр, сайлап алуда катнашучылар) .

2. Субсидия бирү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен бюджет акчасын алучы буларак бюджет акчасы белән баш эш итүчегә – Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

Субсидия турында мәгълүматлар Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы проектын (Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы проектын) формалаштырганда Министрлык тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә урнаштырыла.

3. Субсидия алучылар Министрлык тарафыннан, сайлап алуда катнашучыларның сайлап алу критерийларына туры килүеннән һәм заявкалар керү чиратыннан чыгып, сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучылар җибәргән тәкъдимнәрне (заявкаларны) (алга таба – заявкалар) соратып алу юлы белән үткәрелә торган сайлап алу нәтиҗәләре буенча билгеләнә.

4. Министрлык бердәм порталда һәм үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында https://agro.tatarstan.ru (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты), сайлап алуны үткәрү срогы башлану көненә кадәр өч календарь көннән дә соңга калмыйча, түбәндәгеләрне күрсәтеп, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыра:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкаларны кабул итә башлау яки сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән дә иртәрәк була алмаган

заявкаларны кабул итү тәмамлану датасы (2022 елда заявкаларны кабул итү тәмамлану срогы сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 календарь көнгә кадәр кыскартылырга мөмкин);

Министрлыкның исемен, урнашу урынын, почта адресын, электрон почта адресын;

бу Тәртипнең 15 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

бу Тәртипнең 6 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләрне һәм аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм бу Тәртипнең 7 пункты нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

бу Тәртипнең 8 һәм 9 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) имза куелырга тиешле срокны;

сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) килешү төзүдән баш тарткан (читләшкән) дип тану шартларын;

сайлап алу нәтиҗәләренең бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алуда җиңүчене билгеләгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңрак булмаган урнаштыру датасын.

5. Субсидия алучыларны сайлап алу критерийлары түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бару һәм Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түләү;

Икътисадый эшчәнлек төрләренең гомумроссия классификаторында каралган икътисадый эшчәнлекнең бер яисә берничә төрен гамәлгә ашыру (ОК 029-2014 (КДЕС Ред. 2) – 01.4, 01.5);

хисап һәм (яисә) агымдагы финанс елларда төзелгән 140 баштан 390 башка кадәр куәтле сыер абзарлары һәм (яисә) 500 баштан 5 000 башка кадәр куәтле сарык үрчетү фермалары фермалары булу;

үз-үзен җайга сала торган оешма булган 140 баштан 390 башка кадәр куәтле сыер абзарлары һәм (яисә) 500 баштан 5 000 башка кадәр куәтле сарык фермалары төзегәндә төзелеш контроле үткәрү һәм әлеге эшне башкаручы белгечләрнең Төзелеш өлкәсендәге белгечләрнең илкүләм реестрына кертелүе шарты белән.

6. Сайлап алуда катнашучы заявка бирү датасына түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычы булмау (2022 елда сайлап алуда катнашучы салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча 300 мең сумнан артмаган, түләнмәгән бурыч булырга мөмкин);

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнмәгән бурычлар, шулай ук Татарстан Республикасы каршында акча йөкләмәләре буенча вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычлар юк;

сайлап алуда катнашучылар-юридик затлар үзгәртеп кору процессында (сайлап алуда катнашучы юридик затка кушылу формасында үзгәртеп корудан тыш), банкротлык процедурасы кертелмәгән ликвидация процессында (сайлап алуда катнашучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган, ә сайлап алуда катнашучылар-индивидуаль эшкуарлар индивидуаль эшкуар буларак эшчәнлеген туктатырга тиеш түгел;

чит ил юридик заты, шулай ук Россия Федерациясе Финанс министрлыгы расланган, салым салуның ташламалы салым режимы бирелә торган һәм (яки) мондый юридик затларга карата финанс операцияләрен уздырганда мәгълүмат ачуны һәм бирүне күздә тотмаган дәүләтләр һәм территорияләр (офшор зоналары) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган, устав (җыелма) капиталында чит илләр юридик затларының катнашу өлеше барысы бергә җыеп исәпләгәндә 50 проценттан артмаган Россия юридик заты булмау;

бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмау;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмаска;

2022 елда сайлап алуда катнашучы Россия Федерациясенә, Россия Федерациясе гражданнарына яки Россия юридик затларына карата дусларча булмаган гамәлләр кылучы чит ил дәүләтләре тарафыннан сәяси яки икътисадый санкцияләр кертелү аркасында товарлар кайтарту, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү турында төзелгән дәүләт (муниципаль) контрактларын үтәүдән баш тартуга һәм (яки) чит ил дәүләтләре, чит ил дәүләтләренең дәүләт берләшмәләре һәм (яки) союзлары һәм (яки) дәүләт (дәүләтара) учреждениеләре яки дәүләт берләшмәләре һәм (яки) союзлары тарафыннан чикләү характерындагы чаралар кертелүгә бәйле рәвештә, намуссыз тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) реестрында булмаска тиеш.

7. Субсидия алуга сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучы http://subsidiya.tatar.ru яки http://subsidiya.tatarstan.ru адресы буенча «Минем субсидияләр» мәгълүмат системасының рәсми сайтында (алга таба – сервис) йә «Минем субсидияләр» мобиль кушымтасында, Бердәм дәүләт хезмәтләре һәм

муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталының (www.gosuslugi.ru) «Дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмат-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада идентификацияләүнең һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» мәгълүмат системасында расланган теркәлү язуыннан файдаланып, шәхси кабинет булдыра, аның түләү реквизитлары һәм почта адресы күрсәтелгән, шул исәптән сайлап алуда катнашучының бу Тәртипнең 6 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүе турында мәгълүмат, сайлап алуда катнашучының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлауда катнашучы турындагы, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелә торган заявка турындагы мәгълүматны һәм сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алу белән бәйле булган башка мәгълүматны бастырып чыгару, шулай ук шәхси мәгълүматларны (физик затлар өчен) эшкәртү өчен ризалыгы бирелгән, Министрлык боерыгы белән расланган формада языла торган заявка тутыра һәм түбәндәге документларның сканер ярдәмендә алынган күчермәләрен сервиска кертәләр:

капиталь төзелеш объектының проект документациясенә һәм инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе;

капиталь төзелеш объекты төзелешенең смета кыйммәтен билгеләү дөреслеген тикшерү өлешендә проект документациясенә дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе (аерым тора торган, катлар саны иң күбе ике булган, гомуми мәйданы иң күбе 1 500 кв.метр тәшкил иткән капиталь төзелеш объектлары өчен);

эшләр башкару сыйфатына һәм күләмнәренә төзелеш контролен гамәлдә ашыруны күздә тота торган шартнамә;

җыелма смета исәп-хисабы;

локаль смета исәп-хисаплар;

төзелеш-монтаж эшләрен башкаруга подряд шартнамәләре;

төзелеш контролен гамәлгә ашыручы оешма белән проект документациясенең башкарылган эшләренә оешма белән туры килүенә килештерелгән «Башкарылган эшләрне кабул итү турында акт» дигән КС-2 нче статистик форма буенча белешмә кәгазьләре;

«Башкарылган эшләр һәм чыгымнар кыйммәтләре турында белешмә кәгазе» дигән КС-3 нче статистик форма буенча белешмә кәгазьләрен;

хисап һәм (яки) агымдагы финанс елында башкарылган эшләр өчен түләүне раслый торган түләү йөкләмәләре;

милекендә 140 дан алып 390 башка кадәр куәтле сыер абзарлары һәм (яисә) 500 дән алып 5 000 башка кадәр куәтле сарык фермалары булуны раслый торган документлар.

Сервистан файдаланып тутырылган документларга гади электрон имза куела, гади электрон имзаны куллану турындагы килешү сервиста урнаштырылган оферта шартларын кабул итү юлы белән төзелә.

Әлеге Тәртипнең 5 пунктының икенче һәм өченче абзацларында билгеләнгән критерийларга һәм әлеге Тәртипнең 6 пунктының икенче, дүртенче һәм бишенче абзацларында билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәүгә сайлап алуда катнашучыны тикшерү ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә алына торган мәгълүмат нигезендә сервиста автоматик режимда гамәлгә ашырыла.

Сайлап алуда катнашучы заявканы сайлап алу тәмамланганчы теләсә кайсы вакытта, шул исәптән сервиста сайлап алуда катнашучының бер яисә берничә критерийга яисә таләпләргә туры килмәве турында мәгълүмат алган очракта, сервиста аның туры килүен автоматик режимда тикшерү башкарыла.

Сайлап алуда катнашучы, кирәк булганда, заявкалар кабул итү өчен билгеләнгән срок эчендә заявканы кабат бирергә хокуклы, шул ук вакытта заявка кергән көнендә чират тәртибендә теркәүгә алына.

8. Министрлык:

заявкалар кабул итү турындагы белдерүдә күрсәтелгән сайлап алуны үткәрү срогы тәмамланган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган унбиш көн эчендә аларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән критерийларга һәм таләпләргә туры килү-килмәвен карап тикшерә, Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча сайлап алу нәтиҗәләре турында реестр төзи һәм сайлап алуда җиңүче билгеләү турында  йә заявканы алудан баш тарту турында карар кабул итә;

сайлап алуда җиңүчеләрне билгеләгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңга калмыйча, түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алган сайлап алу нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыра:

заявкаларны карап тикшерү датасы, вакыты һәм үткәрү урыны;

заявкалары карап тикшерелгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килми торган нигезләмәләрен күрсәтеп, заявкалары кабул итүдән баш тартылган сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

килешү төзелә торган субсидия алучының  (алучыларның) исеме һәм аңа бирелә торган субсидия күләме.

9. Заявкаларны карап тикшерү стадиясендә заявканы алмау өчен түбәндәгеләр нигез була:

сайлап алуда катнашучыларның бу Тәртипнең 6 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан тапшырылган заявканың һәм документларның сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә билгеләнгән заявкаларга карата таләпләргә туры килмәве;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның, шул исәптән юридик затның урнашу урыны һәм адресы турындагы мәгълүматның дөрес булмавы;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан заявканың аны бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң бирелүе;

сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 5 пунктында билгеләнгән критерийларга туры килмәве;

бюджет йөкләмәләре лимитының сарыф итеп бетерелүе.

10. Министрлык бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алу нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштырылган көннән  биш эш көне эчендә субсидия алучылар белән

Татарстан Республикасы Финанслар министрлыгы билгеләгән бертип форма нигезендә килешү төзи.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше, күчерү тәртибе;

субсидия бирү нәтиҗәсенең күрсәткече;

субсидия алучы тарафыннан Министрлык билгеләгән өстәмә хисапларны бирү формасы һәм сроклары;

субсидияне кире кайтару тәртибе;

бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән, элек җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитларын килешүдә билгеләнгән күләмдә субсидия бирү мөмкинлеген булдырмауга китерә торган итеп Министрлыкка киметкән очракта, килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар белән ризалашуга ирешә алмаганда килешүне өзү турында шарт (2022 елда килешүнең яңа шартларын, шул исәптән кирәк булганда, башкарма хакимиятнең билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль органы килешү ягы булып тормаган очракта, әлеге орган вәкилләре катнашында килештерү тәртибе).

Кирәк булганда Министрлык субсидия алучылар белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән бертип формалар нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

11. Әлеге Тәртипнең 10 пунктының беренче абзацында күрсәтелгән срокларда субсидия алучы исеменнән эш итәргә хокукы булган зат имзасы белән килешү проектын Министрлыкка тапшырмаган очракта, субсидия алучы килешү төзүдән читләшкән дип таныла.

12. Министрлык:

сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүдә килешүләргә имза кую срогы чыккан көннән бишенче эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкның боерыгы белән рәсмиләштерелә торган субсидия алучыларга субсидия бирү турында карар кабул итә;

субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә акчаны үзенең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счетыннан субсидия алучылар өчен Россия Федерациясе Үзәк банкы яки кредит оешмалары учреждениеләрендә ачылган исәп-хисап яки корреспондентлык счетларына күчерүне гамәлгә ашыра.

13. Субсидия бирелә торган чыгымнар юнәлешләре - төзелеш, монтаж һәм башка төр эшләр чыгымнары, 140тан 390 башка кадәр куәтле сыер абзарлары һәм 500 дән алып 5 000 башка исәпләнгән сарык фермалары төзүгә бәйле, КС-2 номерлы формасы буенча башкарылган эшләрне кабул итү турындагы актларга кертелгән төзелеш, монтаж һәм башка төр эшләр чыгымнары (җиһазлар сатып алуга һәм өстәлгән бәягә салым түләүгә чыгымнардан тыш).

14. Әлеге Тәртипнең 1 пункты (W) (сумнарда) нигезендә субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$W = \sum_{i=1}^{n} (P_1 \times 0,3) + \sum_{k=1}^{r} (P_2 \times 0,3),$$

монда:

i - 140 баштан 390 башка кадәр куәтле сыер абзарлары;

n - 140 баштан 390 башка кадәр куәтле сыер абзарлары саны;

$P_1$ - хисап һәм (яисә) агымдагы финанс елларда кимендә 140 баштан 390 башка кадәр куәтле сыер абзарлары төзүгә бәйле төзелеш, монтаж һәм башка төр эшләр өчен түләүгә фактагы чыгымнар, алар КС-2 формасы буенча башкарылган эшләрне кабул итү турындагы актларга кертелгән (өстәлгән бәягә салымны һәм җиһазлар сатып алуны исәпкә алмыйча), сум;

k - 500 дән 5 000 башка кадәр куәтле сарык фермалары;

r - 500 дән 5 000 башка кадәр куәтле сарык фермалары саны;

$P_2$ - хисап һәм (яисә) агымдагы финанс елларда кимендә 500 баштан 5000 башка кадәр куәтле сарык фермасы төзүгә бәйле төзелеш, монтаж һәм башка төр эшләр өчен түләүгә фактагы чыгымнар, алар КС-2 формасы буенча башкарылган эшләрне кабул итү турындагы актларга кертелгән (өстәлгән бәягә салымны һәм җиһазлар сатып алуны исәпкә алмыйча), сум.

Субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме, җиһазлар сатып алуга һәм өстәлгән бәягә салымны түләүгә чыгымнар керми торып, 140тан 390 башка кадәр куәтле сыер абзары һәм (яисә) сарык үрчетү фермасы төзүгә смета бәясенең 30 процентыннан артыграк була алмый.

15. Субсидия бирүнең нәтиҗәсе - 140 баштан 390 башка кадәр куәтле һәм (яисә) сарыкчылык фермалары саны, агымдагы финанс елның 31 декабренә торышы буенча 500 дән 5 000 башка кадәр куәтле сыер абзарлары саны (берәмлек).

2022 елда субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә килешүдә билгеләгән срокларда ирешү мөмкинлеге булмауга китерә торган шартлар барлыкка килгән очракта, Министрлык, субсидия алучы белән килештереп, субсидия күләмен үзгәртмичә, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү срокларын (әмма иң күбе 24 айга) озайту өлешендә килешүгә үзгәрешләр кертү турында карар кабул итәргә хокуклы. Субсидия күләмен үзгәртмичә, субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү мөмкинлеге булмаган очракта, Министрлык субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткечен киметү турында карар кабул итәргә хокуклы.

16. Субсидия алучы Министрлыкка субсидия бирү нәтиҗәләре мәгънәсенә ирешү турында, субсидия алу елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән типлаштырылган килешү формасы буенча хисап тапшыра.

17. Бирелгән субсидия Министрлыкның тиешле хәбәрнамәсе алынган көннән календарь көннәрдә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемен кире кайтарылырга тиеш:

тулы күләмдә – субсидия алучы тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы факты ачыкланган, субсидия бирелгәндә билгеләнгән, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча шартлар бозылган, субсидия бирү нәтиҗәләре

күрсәткечләренә ирешү турында хисап бирелмәгән очракларда;

субсидия алучы тарафыннан килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешелмәгән очракта, Министрлык субсидия алучыга карата түбәндәге формула

буенча исәпләп чыгарыла торган штраф санкцияләрен ($V_{кайтару}$) куллана, почта аша тапшыру турындагы хәбәрнамәне теркәп, срогын һәм түләү реквизитларын күрсәтеп, килешүдә билгеләнгән, субсидия бирү нәтиҗәләре мәгънәләренә ирешү турында хисап алынган датадан эш көннәрендә исәпләнә торган 60 көн эчендә штраф санкцияләрен куллану турында хәбәрнамә җибәрә:

$$V_{кире\ кайтару} = (V_{субсидия} \times k) \times 0{,}1,$$

монда:

$V_{субсидия}$ – хисап финанс елында субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү максатларында субсидия алучыга фактта бирелгән субсидия күләме;

k – субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешелмәү дәрәҗәсен чагылдыра, түбәндәге формула буенча билгеләнә торган коэффициент:

$$k = 1\ ,\frac{T}{S}$$

монда:

T – хисап датасына субсидия алучы тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәсенең фактта ирешелгән күрсәткече;

S – субсидия алучы өчен килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсенең план буенча күрсәткече.

Штраф санкцияләрен исәпләп чыгарганда бары субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешмәү дәрәҗәсен чагылдыра торган коэффициентның уңай мәгънәләре кулланыла.

2022 елда килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләренә ирешелмәгән өчен штраф санкцияләре кулланылмый.

18. Субсидия алучы тарафыннан бу Тәртипнең 17 пунктында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару срогы бозылганда, Министрлык субсидияне кире кайтару срогы чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган егерме көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри түләтү буенча чаралар күрә.

19. Министрлык субсидия алучыларның субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра.

Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.»;

20. Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешүне мониторинглау килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны тәгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы

тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча гамәлгә ашырыла.

21. Субсидия алучы тарафыннан Министрлыкка тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык субсидия алучыларның тиешле вазыйфаи затларына һәм җитәкчеләренә йөкләнә.

___

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 13 июнь, 554 нче карары белән расланды

Силос-печән траншеяларын ясау эшләрен башкаруга бәйле чыгымнарның бер өлешен каплау өчен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнардан тыш) хисап һәм (яисә) агымдагы финанс елларда башкарылган көндезге каты өслекле силос-сенаж траншеяларын төзү эшләренең үтәлешенә бәйле чыгымнар өлешен (өстәлгән бәягә салым түләүгә чыгымнарны тотып калып) каплауга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү механизмын билгели (алга таба - тиешенчә субсидияләр, сайлап алуда катнашучылар, каты өслекле силос-сенаж траншеялары).

2. Субсидия бирү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә һәм бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен бюджет акчасын алучы буларак бюджет акчасы белән баш эш итүчегә – Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

Субсидия турында мәгълүматлар Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы проектын (Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы проектын) формалаштырганда Министрлык тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) «Бюджет» бүлегендә урнаштырыла.

3. Субсидия алучылар Министрлык тарафыннан, сайлап алуда катнашучыларның сайлап алу критерийларына туры килүеннән һәм заявкалар керү чиратыннан чыгып, сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучылар җибәргән тәкъдимнәрне (заявкаларны) (алга таба – заявкалар) соратып алу юлы белән үткәрелә торган сайлап алу нәтиҗәләре буенча билгеләнә.

4. Министрлык бердәм порталда һәм үзенең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында https://agro.tatarstan.ru (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты), сайлап алуны үткәрү срогы башлану көненә кадәр өч календарь көннән дә соңга калмыйча, түбәндәгеләрне күрсәтеп, сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштыра:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкаларны кабул итә башлау яки сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 30 календарь көннән дә иртәрәк була алмаган заявкаларны кабул итү тәмамлану датасы (2022 елда заявкаларны кабул итү тәмамлану срогы сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 календарь көнгә кадәр кыскартылырга мөмкин);

Министрлыкның исемен, урнашу урынын, почта адресын, электрон почта адресын;

бу Тәртипнең 15 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин ителә торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

бу Тәртипнең 6 пункты нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата таләпләрне һәм аларның әлеге таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеген;

заявкалар бирү тәртибен һәм бу Тәртипнең 7 пункты нигезендә заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

бу Тәртипнең 8 һәм 9 пунктлары нигезендә заявкаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

сайлап алуда җиңүче (җиңүчеләр) тарафыннан субсидия бирү турындагы килешүгә (алга таба – килешү) имза куелырга тиешле срокны;

сайлап алуда җиңүчене (җиңүчеләрне) килешү төзүдән баш тарткан (читләшкән) дип тану шартларын;

сайлап алу нәтиҗәләренең бердәм порталда һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алуда җиңүчене билгеләгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңрак булмаган урнаштыру датасын.

5. Субсидия алучыларны сайлап алу критерийлары түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып бару һәм Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түләү;

Икътисадый эшчәнлек төрләренең гомумроссия классификаторында каралган икътисадый эшчәнлекнең бер яисә берничә төрен гамәлгә ашыру (ОК 029-2014 (КДЕС Ред. 2) – 01.4, 01.5);

